**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге составына керүче Боерган авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

22 ноябрь, 2021 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 22 нояберендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән түбәндәге мәсьәлә буенча гражданнар җыены беркетмәсе тәзелде:

«2022 елда яшәү урыны буенча Боерган авыл җирлеге Боерган авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

1) Боерган авылы Новая урамын төзекләндерү;

2)Боерган авылы Тойгузино, Мирная урамнарында сууткәргеч челтәрен(330м) төзекләндерү;

3) Янгын сүндерү машинасы гаражының түбәсен төзекләндерү.

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 325 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 176 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 174 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенында катнашучы 2 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Боерган авылы гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2022 елда яшәү урыны буенча Боерган авыл җирлеге Боерган авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне:

1) Боерган авылы Новая урамын төзекләндерү;

2) Боерган авылы Тойгузино, Мирная урамнарында сууткәргеч челтәрен(330м) төзекләндерү;

3) Янгын сүндерү машинасы гаражының түбәсен төзекләндерүне хәл итүгә юнәлдерү» буенча карарны кабул ителгән дип таныргa.

3. Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Боерган авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

4. Тукай муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Боерган авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Боерган авыл җирлеге Башлыгы Г.Г.Минакова